РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422054, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт

тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ

КАРАР

03.04.2019

№5

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 19 нчы ноябрендә кабул ителгән 36 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге биләмәсендә физик затларның милкенә салым турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 64 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 24 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында»гы карарына (Советның 2015 нче елның 10 нчы августында кабул ителгән 27 нче, 2015 нче елның 8 нче октябрендәге 8 нче, 2018 нче елның 3нче августында кабул ителгән 15нче, 2018 нче елның 29 нчы ноябрендә кабул ителгән 28 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктнытүбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ 3. Түбәндәге ташламаларне кертергә:

3.1. Ике фатирдан торган күп фатирлы бер катлы торак йорттагы фатирга милек хокукы булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының кадастр бәясендәге салым ставкасының процент елеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә бирелә.

Әгәр фатир гомуми елешле милектә булса, ташламалар суммасы өлешләп милектәге һәр кеше өчен аның бу фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Шул УК вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

3.2. 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнар-физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә.

Салым ташламасы салым салу объектларының чикләнмәгән санына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының теләсә нинди төренә карата бирелә.

Салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар бирергә хокуклы.».

2. Әлеге карарның 2018нче елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә йогынтысын җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/shinar адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз естемә алам.

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Олы Шыңар
авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов